ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СОКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОКОЛКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Школьная, д.38, с. Соколка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422181

Мәктәп ур., 38 нче йорт, Соколка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы.422181

тел.(факс): (85563) 3-82-05; e-mail: Sokol.Mam@tatar.ru, www:mamaduYsh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

“22” ноября 2018 г. — № 64

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Соколка авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы белән, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән «24» сентябрь 2018 елдагы № 2-35 карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Соколка авыл җирлеге
Башкарма комитет
җитәкчесе — А.Г. Рахимзянов

Татарстан республикасы
Мамадыш муниципаль
районы, Соколка авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2018 елның
22 ноябрь № 64 лы
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы,
Соколка авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы, Соколка авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан 2019 елның 28 февраль вакытка кадәр, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән тыш, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә түләнә.

3. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:
а) вакытлыча эшкә сәләтсезлек,
б) хезмәт командировкасы,
гражданнарга гариза нигезендә бер айдан да артмаска тиеш.

4. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарынамуниципаль берәмлекнең мәгълүмат стендларында,Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгаруһәм халыкка җиткерү Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыуставында бигеләнгән тәртиптә,шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыруяки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

5. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге лицевой счетына күчереләләр.

6. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Соколка авыл
җирлеге
башкарма комитетының
2018 елның 22 ноябрь № 64
лы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге
(*муниципаль берәмлек исеме)*
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № ________________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
________________________________________________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________
Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге 919 номерлы карары нигезендә " Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә җирле референдум нәтиҗәләре турында.

Сезгә 2019 елның 28 февраленә көнгә кадәрге вакыт эчендә 2018 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге территориясендә җирле референдум чараны гамәлгә ашыру буенча 500 сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк: ТР буенча ФКИ (ТР Мамадыш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы)
Кабул итүче як банкы БИК Бүлекчәсе –НБ Татарстан Республикасы БИК049205001
Сч. № 40101810800000010001
Кабул итеп алучы Сч. № ____________________________________________
ИНН 1626008921
КПП 162601001
КБК 605 117 14030 10 0000 180 ОКТМО 92638475
Түләүнең билгеләнеше

Җитәкче __________________ А.Г. Рахимзянов
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге
(*муниципаль берәмлек исеме)*

бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне 500 сум күләмендә түләү турында № ________ белдерү кәгазе.
Түләүченең Ф.И.Ә.и. ____________________________________________________________
Адрес:
________________________________________________________________________________
Кабул ителде «__» _____________ 20__ ел.
__________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм Соколка авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*